| СОВЕТ<br>ПОПОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ПОПОВКА<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.06.2024 г. Поповка авылы № 114

«Җирле салымнар суммалары
өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз
дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү
турында» 2023 елның 29 маендагы
79 номерлы Поповка авыл җирлеге
советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Поповка авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Поповка авыл җирлеге Советы КАРАР:

1. «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2023 елның 29 маендагы 79 номерлы Попов авыл җирлеге советы карарына (09.02.2024 номерлы 101) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2. 1 пунктны түбәндәге пунктча белән тулыландырырга:

8) физик затларның җирле салымнар буенча бурычы булу Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар узганнан соң 500 сумнан артмаган сумма.»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Баулы муниципаль районы сайтында bavly.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз йогынтысын кертә.

Совет башлыгы, рәисе С.А. Попов